җан башына дифференциациялəп исəплəнгəн нормативлары буенча иминлəштерүче медицина оешмаларына кергəн акчалар суммасыннан 0,95 процент күлəмендə күздə тотыла.

Мəҗбүри медицина иминияте системасының тотрыклылыгын тəэмин итү өчен Фонд бюджетында Фондның нормалаштырылган иминият запасы акчалары күлəме 2025 елга – 9 027,3 млн. сум, 2026 елга – 9 631,1 млн.сум, 2027 елга 10 100,2 млн.сум күлəмендə билгелəнде. Бу акчалар түбəндəгелəргə җибəрелəчəк:

медицина ярдəменə түлəү өчен җитешми торган акчаны иминлəштерүче медицина оешмасына бирү юлы белəн мəҗбүри медицина иминияте программасын тормышка ашыруны өстəмə финанс белəн тəэмин итүгə;

иминлəштерелгəн затларга мəҗбүри медицина иминияте полисы бирелгəн Россия Федерациясе субъекты территориясеннəн читтə күрсəтелгəн медицина ярдəме өчен мəҗбүри медицина иминиятенең база программасында каралган күлəмдə исəп-хисап ясауга;

квалификация күтəрү программалары буенча медицина хезмəткəрлəренə өстəмə һөнəр белеме бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазлары сатып алу һəм ремонтлау чараларын финанс белəн тəэмин итүгə;

гадəттəн тыш хəл шартларында һəм (яисə) əйлəнə-тирəдəгелəр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу янаганда территориаль мəҗбүри медицина иминияте программасы белəн билгелəнгəн медицина ярдəме күлəмнəре кимтелүгə бəйле рəвештə медицина оешмаларына алып бетерелмəгəн керемнəрен компенсациялəү чараларын финанс белəн тəэмин итүгə.

2025 елда, 2026 һəм 2027 еллар план чорынла Фонд бюджеты баланслана һəм кытлыксыз планлаштырыла.

